ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:
«18) техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналарның идарәче компанияләре тарафыннан – махсус икътисадый зоналар төзү турындагы килешүләрне гамәлгә ашыру максатларында булдырылган һәм идарәче компания балансында төп чаралар объекты буларак санала торган мөлкәткә карата, күрсәтелгән мөлкәтне исәпкә куйган айдан соң килә торган айдан башлап ун ел узгач, мөлкәтнең исәбен аерым алып бару шарты белән.»;
б) $3^1$ өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:
«3) техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналарның идарәче компанияләре – махсус икътисадый зоналар төзү турындагы килешүләрне гамәлгә

ашыру максатларында булдырылган һәм идарәче компания балансында төп чаралар объекты буларак санала торган мөлкәткә карата, күрсәтелгән мөлкәтне исәпкә куйган айдан соң килә торган айдан башлап ун ел узгач, мөлкәтнең исәбен аерым алып бару шарты белән.»;

2) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле 14 һәм 15 пунктлар өстәргә:

«14) 2029 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 18 пунктын;

15) 2032 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы $3^1$ өлешенең 3 пунктын.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасыннан һәм 2 пунктының өченче абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасы һәм 2 пунктының өченче абзацы 2029 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 18 пункты нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы 2025 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 30 сентябрь
№ 60-ТРЗ